**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«11» 12 2024 ел Яр Чаллы ш. № 5531

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Березка» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 январендәге 4 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Березка» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 1 кушымта нигезендә расларга.
2. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Березка» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 20 октябрендәге 3526 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

И.о. Руководителя
Исполнительного комитета К.Р. Назмиев

Муниципаль район Башкарма комитетының 2024 елның «11» 12 5531 номерлы карарына 1 кушымта

2024 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Березка» балалар бакчасы буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Оста бармаклар» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Яз, укы» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 3 | «Бер баскыч, ике баскыч» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 4 | «English is fun» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 5 | Биюләр «Каблучок» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районы
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем
бирү учреждениесе - «Березка»
балалар бакчасы мөдире ____________ В.В. Зингарова

«Бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт
күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчесе урынбасары ____________ Р.Р. Йосыпова

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Березка» балалар бакчасы тарафыннан түләүле хезмәт күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

**1. «Оста бармаклар» - п**рограмма кулларның вак моторикасын үстерүгә һәм ныгытуга юнәлдерелгән. Әлеге хезмәт 4 яшьтән алып 5 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 60,4 кв.м, балалар саны - 15.

Дәресләр атнага бер тапкыр үткәрелә.

**2. «Яз, укы»** - балаларны мәктәпкә әзерләү (сөйләм үстерү, грамотага өйрәтү). Әлеге хезмәт 5 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 47,9 кв.м, балалар саны - 15.

Дәресләр атнага бер тапкыр үткәрелә.

**3. «Бер баскыч, ике баскыч»** - балаларны мәктәпкә әзерләү (математик күзаллауларны үстерү). Әлеге хезмәт 5 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 47,9 кв.м, балалар саны - 15.

Дәресләр атнага бер тапкыр үткәрелә.

**4. «English is fun»** - сөйләм күнекмәләрен үстерүгә, тел мохитенә чумуга һәм чит телне өйрәнүгә кызыксыну уятуга юнәлтелгән. Әлеге хезмәт 5 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 47,9 кв.м, балалар саны - 7.

Дәресләр атнага бер тапкыр үткәрелә.

**5. Биюләр «Каблучок»** - программа балаларның музыкаль һәм иҗади сәләтләрен формалаштыруга юнәлтелгән. Әлеге хезмәт 4 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 51 кв.м, балалар саны – 10.

Дәресләр атнага бер тапкыр үткәрелә.

ТР Тукай муниципаль районы
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем
бирү учреждениесе - «Березка»
балалар бакчасы мөдире ________________ В.В. Зингарова